Сара Садыйкова

Ил кызы
Дочь Родины

3 1761 12054616 3

M
1619
.S23
2009
MUSIC

Digitized by the Internet Archive
in 2026 with funding from
University of Toronto

https://archive.org/details/31761120546163

«Ищите свою тропинку
к душе народной...»

Сара Садыйковага

Ай нурында, су юлында, һай, нурында моң тулы,
Талпынасың, көрсенәсең, гөл сибәсең, Ил кызы.
Син шаһит та, син бәхет тә, син өмет тә, су юлы.
Ак чиләкләр, ак беләкләр, ал йөзеңдә ай нуры.
Җырларыңда, моңнарыңда нинди өннәр дулкыны,
Алсу таңнар очкыны да, айлы төннәр тылсымы.
Куккә менә, җиргә иңә, җанга сеңә ил моңы;
И, сагышлы, иң сылу кыз, кайдан алдың син моны?!

Гамил Афзал, 1973 ел

Сара Садыйкова

Ил кызы

Җырлар

Дочь Родины

Песни

Казань
2009

УДК 821.512.145-1-93:784
ББК 84(2Рос=Тат)-5:85.319
С14

Төзүчесе – Әлфия Айдарская
Музыкаль мөхәррире – Рәшит Моратов

Составитель – Альфия Айдарская
Музыкальный редактор – Рашид Муратов

Садыйкова Сара
С14 Ил кызы : җырлар / С.Садыйкова; төз. Ә.Г.Айдарская. – Казан : «Дом печати» нәшрияты, 2009. – 180 б.

Садыкова Сара
С14 Дочь Родины : песни / С.Садыкова; сост. А.Г.Айдарская. – Казань: Дом печати, 2009. – 180 с.
ISBN 978-5-94259-196-0

Басмада легендар татар җырчысы һәм композиторы Сара Садыйкованың нәшер ителмәгән 60 җыры тупланды. Җыентык композиторның иҗади мирасы һәм татар халкының музыкаль хәзинәсе белән кызыксынучы профессиональ җырчыларга тәкъдим ителә.

В сборнике собраны ранее неизданные 60 песен легендарной татарской певицы и композитора Сары Садыковой. Издание адресуется профессиональным певцам, интересующимся творческим наследием композитора и музыкальным сокровищем татарского народа.

ISBN 978-5-94259-196-0
© Айдарская А.Г., 2009

Төзүчедән

Легендар Сара Садыйкова милли сәнгатебезгә үзенең халыкчан моңы белән килеп керде. Югары музыкаль белемле беренче профессиональ татар җырчысы буларак (Мәскәү консерваториясе – 1922–1928 һәм 1934–1938), ул беренче татар операсы «Сания»да төп партияне тәүге мәртәбә башкарды.

Сара Садыйкованы халык искиткеч драма артисткасы итеп тә (Мәскәү Татар драма театры – 1923–1930, Г.Камал исемендәге театр – 1930–1934), иҗади эшчәнлеге сәнгать югарылыгына менгән оста башкаручы, Татарстан милли опера сәнгате үсешенә зур өлеш керткән (Татар дәүләт опера һәм балет театры – 1939–1948) опера җырчысы итеп тә хәтерли. Бәхеткә, аның Көнбатыш Европа һәм рус классикасында тәрбияләнүе «татар халкы кызы» булып калуына комачауламады: аның туган халык фольклорын бик яхшы белүе, татар халык җырларын дөрес итеп һәм тирән моң белән башкаруы үзенең дә милли көйләренең дәрәҗә-абруен бик күтәрде.

Җырчы да, композитор да буларак, аның иҗаты иң элек үзенең кабатланмас моңы белән бәһасез. Сара Садыйкова әсәрләре төрле темаларга һәм төрле жанрга бай, күпкырлы. Салмак агышлы лирик җырлар, шаян, батырлык һәм патриотик, мәхәббәт-дуслык җырлары, күңелле вальслар, романслар, маршлар, киң сулышлы күмәк җырлар, танго-фокстротлар, бию ритмнары – барысы да ачышлы. Нинди генә жанрда язса да, композитор үзенең әсәрләрендә үз халкының рухын саклый, җырларын төрле борылмалар белән бизи. Алар әйтерсең лә ноталарның биш юлына сыеп бетә алмый. Аларны, киңлеккә юллап, мәхәббәт белән халык күңеленә җиткерә. Аның җырын җырламаган җырчы юктыр, мөгаен. Җырлары үз заманының ачышын актив сурәтли. Шуның белән алар мәгънәле дә. Бөек Ватан сугышы чорында «Көтәм сине», Г.Камал исемендәге театрның 50 еллыгына «Театрыма» дигән җырлар барлыкка килә. Космоска беренче кеше оча – «Юрий Гагарин»... Бу композиторның соңгы көннәренә кадәр дәвам итәчәк...

Юмарт, киң күңелле кеше буларак, ул үзенең истәлекле вакыйгаларга, шәхесләргә, республика авыл-шәһәрләренә багышлап язган җырларын аерым җырчыларга, музыкантларга рәхәтләнеп таратты. Шуңа да аның

От составителя

Легендарная Сара Садыкова пришла в наше национальное искусство своим музыкальным звучанием. Первая татарская профессиональная певица с высшим музыкальным образованием (Московская консерватория – 1922–1928 и 1934–1938) явилась и первой исполнительницей заглавной партии в первой татарской опере «Сания».

Народ помнит Сару Садыкову и как замечательную драматическую актрису (Московский Татарский драматический театр – 1923–1930 и театр имени Г.Камала – 1930–1934), и как оперную певицу (Татарский театр оперы и балета – 1939–1948), чья творческая деятельность достигла высоких эталонов художественного и исполнительского звучания и мастерства, внесшую огромный вклад в развитие профессионального вокального исполнительства, в создание национального оперного искусства в Татарстане. Воспитание на западно-европейской и русской классике, к счастью, не помешало ей остаться «дочерью татарского народа»: великолепное знание родного фольклора, достоверность мелодий татарских народных песен и глубокий задушевный «моң» в ее исполнении явились в дальнейшем главным фактором небывалой популярности в народе ее музыкальных сочинений.

Творчество ее и как певицы, и как композитора бесценно, прежде всего, своим неповторимым «моң». Произведения Сары Садыковой разнообразны по тематике и жанру: протяжные, лирические, шуточные, героико-патриотические, о любви и дружбе, веселые вальсы, романсы, фокстроты, танго, марши, массовые песни, танцевальные ритмы и т.д. В каком бы жанре композитор не писала, в своих произведениях сохраняет душу своего народа, украшает свои песни, используя всевозможные мелизмы (излияния души), не умещающиеся, казалось бы, в пяти линейках нотного стана, вплетая их в мелодию словно кружево. Обогащает их и с любовью дарит народу. Не было, пожалуй, певца, не исполнявшего ее песни. Они тем и значительны, что активно отражали процесс течения своей исключительной эпохи. Великая Отечественная война и, появляется танго «Жду тебя», к 50-летию театра имени Г.Камала – песня-посвящение «Моему театру», полет первого человека в космос – песня «Юрий Гагарин»... Это продолжится в течение всей жизни композитора...

Как человек доброй и широкой души, посвящая свои песни конкретным событиям, да-

жырларының күбесе шәхси кулларда истәлек булып калды.

Бүгенге көндә аның 207 җыры җиде нота җыентыгында урын алды.

Сара Садыйкованың җыр иҗаты татар эстрада сәнгатенең чыганагы булды һәм аның үсешендә зур роль уйнады, яшьләр иҗатына яңа этәргеч булды. Ул халыкчанлыгы, әсәрләрендә заманча аһәңнәре, ритмнары белән йөрәкләргә үтеп керде, өмет уятуы белән һәм зур оптимистлыгы белән аерылып тора. Композитор татар музыкасының җыр тарихында иң беренче булып танго, фокстрот, блюз стилен файдаланды. Бүген Сара Садыйкова татар эстрада һәм хәзерге заман татар җырлары сәнгатендә классик дигән исемгә чын мәгънәсендә лаек.

Сезнең игътибарыгызга бу җыр җыентыгына магнитофон тасмасына язылган, ләкин нәшер ителмәгән җырлар керде. Шулай ук моңарчы ишетелмәгән, онытылган, үзенең җырчысын һәм тыңлаучысын күп еллар архивында көтеп яткан җырлар да керде. Алар клавир формасында тавыш һәм фортепиано өчен тәкъдим ителә. Бу җырлар, әлбәттә, бүтән аһәңле музыкаль формаларда да яңгырарга мөмкин. Ләкин без искиткеч моңлы, үзенчәлекле көйләрне, аларның фактурасын, алар эчендәге артистлык табигатен һәм композиторның үзенә генә хас җырчылык сәләтен саклап калу нияте белән эш иттек.

Бу җентекле, иҗади рухландыргыч эштә җыентыкның музыкаль редакторы – Татар дәүләт гуманитар-педагогия университетының доценты Рәшит Моратовның өлеше бик тә җитди һәм зур. Мин аңа чиксез рәхмәтле.

Җырлар җыентыгына Сара Садыйкованың фәнни рәвештә архив тасвирламалары һәм аның тулы музыкаль язмалары турында мәгълүматлар да кертелде.

Әлеге җыр җыентыгы Сара Садыйкованың музыкаль талантын сөюче яшь дусларым Эльнар Җамалиев һәм Рөстәм Рәхмәтуллинның матди ярдәме белән дөнья күрде. Аларга чын йөрәгемнән, мәрхүм Сара Садыйкова рухын кушып, зур рәхмәтләремне белдерәм. Шундый улларыбыз булганда, халкыбыз рухи байлыгын югалтмас һәм мәңгелеккә саклар!

там, городам и селам своей республики, щедро раздавала их певцам и музыкантам. И многие ее песни оседали в личных архивах как память.

На сегодняшний день изданы ее 207 песен в семи нотных сборниках.

Песенное творчество Сары Садыковой сыграло большую роль в развитии татарской эстрадной и бытовой песни, его влияние на творчество молодых бесспорно. Оно отличается свежими, современными по звучанию и ритму интонациями, народностью, проникновенностью и большим оптимизмом. Композитор впервые в песенной истории татарской музыки использовала стиль танго, фокстрота, блюза. Сегодня Сара Садыкова по праву является классиком татарской эстрадной и бытовой песни.

Вашему вниманию в настоящий сборник вошли, прежде всего, записанные на магнитную ленту, но не изданные песни композитора, в т.ч. популярные. Собраны также неизвестные, забытые, десятилетиями хранящиеся в ее архиве, ждущие своего исполнителя и слушателя. Они предлагаются в форме клавира для голоса и фортепиано. Песни эти могли бы звучать и в иных музыкальных формах, но мы стремились сохранить фактуру уникальных мелодий, несущих в себе артистическую природу и богатый певческий дар самого композитора.

И в этой кропотливой, творчески одухотворенной работе большая заслуга музыкального редактора сборника, доцента Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета Рашида Муратова, которому я бесконечно благодарна.

В данном сборнике песен дается научная справка об архиве композитора и информация о полном собрании сочинений Сары Садыковой.

Сборник песен появился на свет лишь благодаря моральной, организационной и финансовой помощи больших поклонников музыкального таланта Сары Садыковой – моих молодых друзей Эльнара Замалиева и Рустама Рахматуллина. От чистого сердца приношу им огромную благодарность. Когда есть такие сыны, народ наш не утратит и сохранит навечно свое духовное богатство!

Музыкаль мөхәррирдән

Сара Садыйкова – татар халкының XX гасырда иң танылган җырчы-сандугачы һәм композиторы. Аның җырлары һәм спектакльләргә язылган көйләре халык арасында киң таралган һәм яратып башкарыла. Данлыклы профессиональ җырчы буларак, С.Садыйкова татар җырларының аһәңен, табигатен, моңын тирән аңлый, шуңа күрә аның бөтен иҗаты моң, аһәң белән сугарылган. Моң – Сара Садыйкова музыкасының нигезе.

Композитор татар иҗат әһелләре белән тыгыз элемтәдә яши. Шагыйрьләр аның җырларына шигырьләр язалар, композиторлар аның көйләрен эшкәртәләр, режиссерлар спектакльләргә көйләр язарга үтенәләр.

Бу җыентыкка элек бастырылмаган әсәрләр кертелде. Эш барышында архив материаллары һәм магнитлы язмалар кулланылды. Музыкаль мөхәррир оригиналлар белән бик сакчыл эш итте: җырларның көйләре һәм метроритм башлангыч хәлендә калдырылды, җырларны эшкәрткәндә С.Садыйкованың өслүбе истә тотылды.

Бу җыентыкта танылган, билгеле җырларның бастырылуын ният итеп куймадык, безнең максат – күренекле татар композиторы Сара Садыйкованың иҗатын киләчәк буыннарга калдыру.

Тагын җыентыклар бастырып булыр дип ышанып калабыз...

От музыкального редактора

Сара Садыкова – одна из самых популярных татарских композиторов-песенников XX столетия. Ее песни и музыка к спектаклям широко известны и любимы татарским народом. Будучи известной профессиональной певицей, С.Садыкова глубоко чувствовала природу татарской песни, ее душу (моң), поэтому все ее музыкальное творчество пронизано мелодизмом. Мелодия – основа музыки Сары Садыковой.

Композитор тесно сотрудничала с татарской творческой элитой. Поэты писали тексты к песням, композиторы делали обработки ее мелодий, режиссеры заказывали музыку к спектаклям.

В данный сборник вошли произведения, ранее неизданные. При работе были использованы архивные материалы и записи с магнитных лент. Музыкальный редактор бережно отнесся к оригиналам, оставив в первоначальном виде метроритм и мелодии песен, при обработках песен учитывалась стилистика С.Садыковой.

Нашей общей задачей являлось не издание известных популярных песен автора, наша задача – оставить творческое наследие замечательного татарского композитора Сары Садыковой потомкам.

Надеемся на издание следующих сборников...

"Сания" операсыннан Сания ариясе

махсус Сара Садыйкова тавышына

Ария Сании из оперы "Сания"

для голоса Сары Садыковой

Л. ЛЮБОВСКИЙ *реставрациясе*
Р. АЙМӘТ *сүзләре*

Солтан ГАБӘШИ,
Газиз ӘЛМӨХӘММӘТОВ,
Василий ВИНОГРАДОВ *музыкасы*




ми, ут - та ян - ды күп - ме көн - - нә - рем.
Бер - гә бу - лыйк ди - - - еп ку - лын суз -
гач, кул - - ла - - рым - - - - -
-ны ни - гә бир - - -
mf


rit.
5
- - - - мэ - - - - дем?
3
p
Vivo
f
cresc. accell.
Tempo I
Таң - да чы-гып сах - ра-лар-
3


га сер - лə - рем - не чиш - тем
жил - лəр - гə, са - гы - шым - ны ю - ды а - гым су -
rit.
Tempo I
- лар, бу га-зап- ка, бел - мим, ниш - лəр -
гə? Кул - ла - ры - ма а - лам хат - лар - ны,
pp


а - лар ми - ңа из - ге, ка - дер - ле.
rit.
A tempo, espressivo
Яшь йө - рә -
гем hа - - ман эз - гә - лә - нә, ү - ке -


-неч - ләр те - лә бә - - гырь - не.
ff
Meno mosso, espressivo
p
Яз - мыш - лар - дан уз - мыш юк, Яз - мыш - лар - дан
p
уз - мыш юк...
p
pppp

1925 ел

Театрыма

Моему театру

50-летию театра им. Г. Камала

Сара САДЫЙКОВА *сүзләре*





Илгә нурлар чәчеп яшәдең,
Хөрмәтле театрыбыз.
Илле яшең белән бүген без,
барыбыз да Сине котлыйбыз.

Синдә тудым, Синдә үстем,
Синдә булды бар ямем.
Синдә картайдым, театрым,
Котлы булсын бүген бәйрәмең!

Мәңге яшә, Син, театрым!
Ил күгендә кояш булып.
Яңа уңышлар теләп Сиңа,
Калабыз без дусларың булып.

Без икәүләп яккан учак

Очаг, зажженный вдвоем

Башкирскому певцу Габдрахману ХАБИБУЛЛИНУ посвящается...

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*

Tempo di Valse





1958 ел

Без икәүләп яккан учак
Янар әле, сүнмәс әле.
Күңел суыта торган җилләр
Арабызга кермәс әле.
Эчкерсезлек чишмәләре
Кипмәс әле, кипмәс әле.

Без үстергән зәңгәр гөлләр
Үсәр әле, шиңмәс әле.
Ап-пак кырау тузаннары
Өмет гөленә төшмәс әле.
Саф мәхәббәт ефәк җебен
Сүтмәс әле, сүтмәс әле.

Җылы язлар, алсу таңнар,
Матур көннәр үтмәс әле.
Яшьлек безгә: "Хушыгыз!" дип,
Кулын болгап китмәс әле.
Чынаякларда бәхет балы
Бетмәс әле, бетмәс әле!..

Гомеремне түләп...

Ценою жизни ...

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА *сүзләре*





1963 ел

Сүзләре 2008 елда язылган

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды шигъри дөнья,
Бәллүр бишегендә тирбәтеп,
Бәллүр бишегендә тирбәтеп.

Йөрәкләрне әсир итте Сөю,
Әсир итте йөрәкләрне,
Шул Сөюнең шигъри ширбәте,
Шул Сөюнең шигъри ширбәте.

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды шигъри дөнья
Сөю назларында көйдереп,
Сөю назларында көйдереп.

Гомеремне түләп җырлар яздым,
Гомеремне түләп яздым,
Шигырь буынына сеңдереп,
Шигырь буынына сеңдереп.

Ямьле Тол буйлары

Прекрасны берега Тобола

Мостафа НОГМАН *сүзләре*





1967 ел

Урал таулары артыннан
Кызарып таңнар ата.
Күк томаннарга күмелгән
Тол буйларын уята.
 Һай! Ямьле Тол буйлары,
 Яңгырый җырда макталып,
 Тол буенда хезмәт белән
 Шатланып яши халык.

Тол буйлары, тугайлары
Яшәрә язгы таңда.
Казанбаев кебек батыр
Егетләр үсә анда.
 Һай! Ямьле Тол буйлары,
 Сулары борылып ага,
 Тол буенда үскән яшьләр
 Зур тормышка юл ала.

Тол буйлары, тын сулары
Яшел бөдрә тал-тирәк,
Гөрләсен безнең яклар, дип,
Ашкына безнең йөрәк!
 Һай! Ямьле Тол буйлары,
 Әрәмәле урманы,
 Кая гына китсәк тә без,
 Онытасыбыз юк аны!

Арчалылар бит без (Син йөрәктә минем)

Мы ведь арские (Ты в сердце моем)

Сибгат ХӘКИМ *сүзләре*




ча ямь-ле, ур-ман-кыр-лар я - гы, Ар - ча дан-лы Ту-кай- Кыр-лай я -
гы. Шу-ңа кү-рә го-рур, гөр-ләп ү-тә го-мер, Ар-ча-лы-лар без бит Ар-ча-
1. лар. Ар - //лар.
2.
Coda
rit.
Ар - //ләп ү - тә го-мер,
A tempo
poco a poco rit.
Ар-ча-лы-лар,без бит Ар-ча - лар.
ff

1978 ел

Арча, Арча, бөтен дөнья сокланыр як.
Батырларың эштә ярышалар.
    Арча ямьле, урман-кырлар ягы,
    Арча данлы Тукай-Кырлай ягы.
    Шуңа күрә горур, гөрләп үтә гомер,
    Арчалылар, без бит Арчалар. } 2 тапкыр

Арча, Арча, бөтен дөнья сокланыр як.
Зәңгәр күлләр, матур бакчалар.
    Син йөрәктә минем җырым төсле,
    Халкым эшчән, кыю, батыр, көчле.
    Шуңа күрә горур, гөрләп үтә гомер,
    Арчалылар, без бит Арчалар.

Арча, Арча, бөтен дөнья сокланыр як.
Мәңге изге синең туфрагың.
    Арча - оста читекләр ягы,
    Читекләргә чигелә Арча даны.
    Шуңа күрә горур, гөрләп үтә гомер,
    Арчалылар, без бит Арчалар.

    Арчалылар, без бит Арчалар.

Елыш авылы көе

Мелодия деревни Елыш (Сабинский район)

Сара САДЫЙКОВА *сүзләре*




жыр - лый пе - чән ча - ба е - гет - лә - ре, кыз - ла -
3
ры. Жыр - лый - жыр - лый пе - чән ча - ба е - гет -
3
3
Кабатлау өчен
Coda
-лә - ре, кыз - ла - ры.
//ре.
p

1963 ел

Елыш авылы бигрәк матур,
Ямьле болын-кырлары.
Җырлый-җырлый печән чаба
Егетләре, кызлары.
Җырлый-җырлый печән чаба
Егетләре, кызлары.

Киң кырларга, болыннарга
Без чыгабыз һәр таңда.
Тырыш хезмәт, мул уңышлар
Булыр бездән Ватанга.
Тырыш хезмәт, мул уңышлар
Булыр бездән Ватанга.

Сөйгән ярымны күзәтәм,
Йөрәкләр өметләнә.
Сөям ди аның йөзләре,
Кара моңлы күзләре.
Сөям ди аның йөзләре,
Кара моңлы күзләре.

Балтачым - туган ягым

Родная сторона Балтаси

Самат ШАКИР *сүзләре*





Балтач болынында уйнап үстем,
Тәмле чишмә суларын эчтем.
Кая гына китеп йөрсәм дә мин,
Туган ягым, исемә төштең.

Кушымта:
Кырларым, суларым,
Кадерле туган ягым!
Синдәй ямьле, суы тәмле
Нинди генә җирләр бар тагын! } 2 тапкыр

Өзелеп сөйгән ярым синдә генә,
Синдә минем зәңгәр кичләрем.
Синдә эшләп үстем, канат җәйдем,
Синдә туды тәүге хисләрем.
Кушымта.

Бала чагымнан ук сиңа гашыйк,
Балтач - тирә якта данлы ул!
Хезмәт сөя батыр егет-кызлары,
Балтач халкы олы җанлы ул.
Кушымта.

Заһид жыры

"Оныталмасаң нишләрсең" спектакленнән

Песня Загида

из спектакля "Если не забудется"

Хәй ВАХИТ *сүзләре*





1977 ел

Истә һаман авыл урамнары,
Күз алдымда болын юлларым.
Гармун тартып зәңгәр кичләреңдә,
Шунда үтте яшьлек елларым.

Шунда калды шаян-шат җырларым,
Каеннарның кунып ялына.
Эзләп кайтсам яшьлек эзләремне,
Тынгы тапмам микән җаныма.

Туган як арышлары

Хлеба родной стороны

Хәйдәр ГӘЙНЕТДИНОВ *сүзләре*





Йөгерә дулкын-дулкын булып,
Туган як арышлары.
Йөгерә дулкын-дулкын булып,
Туган як арышлары.
Офыкларны узып китеп,
Офыкларны узып китеп } 2 тапкыр
Каядыр барышлары.

Яшел дулкын әнкәйләрнең
Өметле сагышлары.
Яшел дулкын әнкәйләрнең
Өметле сагышлары.
Шундый рәхәт, шундый җылы,
Шундый рәхәт, шундый җылы } 2 тапкыр
Күңелгә кагышлары.

Күзләр килде. Күпләр кайтты.
Ә кемдер кавышмады.
Күзләр килде. Күпләр кайтты.
Ә кемдер кавышмады.
Саргайды инде, саргайды,
Саргайды инде, саргайды } 2 тапкыр
Дулкынның агышлары.

Йөгерә дулкын-дулкын булып
Туган як арышлары.
Йөгерә дулкын-дулкын булып
Туган як арышлары.
Офыкларны узып китеп,
Офыкларны узып китеп } 2 тапкыр
Каядыр барышлары.

Туган як арышлары...

Балкый Шәйморза утлары

Мерцают огни шайморзинские

Мостафа НОГМАН *сүзләре*




mf
- за, Шәй-мор - за, туган жи - р(е)без Шәй - мор - за. Без - нең
яшь - лек ел-ла-ры - быз гөр ки - леп син - дә у - за. Без - нең
1.
2.
Coda
за.
f
//леп син - дә у - за.
f
rit.

1968 ел

Балкый Шәйморза утлары
Зәңгәр таңнарга кадәр.
Шәйморзаны оныта алмыйсың
Бер барып күрсәң әгәр.

К у ш ы м т а:

Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза.
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза. } 2 тапкыр

Макталмый безнең Шәйморза
Урманнар, күлләр белән.
Балкый ул кайнар йөрәкләр,
Якты күңелләр белән.

К у ш ы м т а.

Яшь кызларын, егетләрен
Шәһәрләр, ВУЗлар тарта.
Бик күпләре канатланып
Туган якларга кайта.

К у ш ы м т а.

Яңара безнең Шәйморза,
Нурланып үсә һаман.
Илебез күгендә янган
Якты бер йолдыз сыман.

К у ш ы м т а:

Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза.
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза. } 2 тапкыр

Табигать куенында

В объятиях природы

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА *сүзләре*




Allegretto
син ку - на - сы тал - лар - ны.
Сан - ду - гач, сай - ра син,
tr
rit.
тиб - рә - теп тал - ти - рәк - не.
Син сай - ра саң, җәй - ге таң - нар жил кен - де - рә йө - рәк - не.
3
Allegretto
Coda
A...
A...
A...
rit.
A tempo
A...
A...
A...
mf
1963 ел

Сандугач, сандугач,
Сайра, сайра таң тугач.
Тарат дәртле моңнарны,
Макта җәйге таңнарны.
Таң җилләре назласын
Син кунасы талларны.

Сандугач, сайра син,
Тибрәтеп тал-тирәкне,
Син сайрасаң, җәйге таңнар
Җилкендерә йөрәкне.

Сандугач, сандугач,
Сайра, сайра таң тугач.
Әрәмәдә, болында,
Сайра илем турында,
Оя яса куанып,
Табигатьнең куенында.

Сандугач, сайра син,
Тибрәтеп тал-тирәкне.
Син сайрасаң, җәйге таңнар
Җилкендерә йөрәкне.

Туган авылым каршымда

Родная деревня передо мной

Мостафа НОГМАН *сүзләре*





Ераклардан карап киләм
Чынлы басуларына.
Шунда тынгы табылыр кебек
Күңелем ярсуларына.

К у ш ы м т а:
Туган авылым минем каршымда, } 2 тапкыр
Күңелем һаман омтыла шунда.

Чынлы суы җәелеп ага,
Язгы ташкыннар килсә.
Ташкыннар кебек шаулашып
Авылымда яшьләр үсә.

К у ш ы м т а:
Туган авылым минем каршымда, } 2 тапкыр
Күңелем һаман омтыла шунда.

Шушы кырлар буйлап минем
Яшьлек юлларым үткән.
Шул юллардан яшьлек дустым
Елмаеп чыкса икән.

К у ш ы м т а:
Туган авылым минем каршымда, } 2 тапкыр
Күңелем һаман омтыла шунда.

Салават

Салавату Юлаеву посвящается...

Әхмәт ГАДЕЛ *сүзләре*





1981 ел

Давылларны гизеп килгән дә,
Горур башын артка чөйгән дә,
Еракларга карап Салават,
Туктап калган Идел ярында.
Утлар кайный егет канында.
Утлар кайный егет канында.

Аргамагы - дускае-аты,
Батыр Салаватның канаты.
Текә ярны тоеп туктаган,
Ярсу башын чайкый җилләрдә,
Ир батырны тоеп иярдә.
Ир батырны тоеп иярдә.

Агыйделнең биек ярыннан
Егет карый газиз иленә.
Һаман сакта тора Салават.
Башкорт-йортның гүзәл җиренә
Тия күрмәсен дип, җиле дә.
Тия күрмәсен дип, җиле дә.

Садыйк-комиссар

Садыку Ахтямову посвящается...

Мөхәммәт ХӘМИТОВ *сүзләре*



Утны, суны кичте, ерак илләр гизде,
Яуда җиңде Садыйк - комиссар.
Үлем читләп узды, якын килмәс булды,
Куркытты аны Садыйк - комиссар.

Азатлыкны яклап, ил язмышын аклап,
Көрәште ул, Садыйк - комиссар.
Идел күперен саклап, дошман явын таптап,
Таң калдырды, Садыйк - комиссар.

Тирә-якта дошман, авыл куркып пыскан,
Моңсу иде ул көн каеннар.
Яшен кебек атылып, карабинын асып,
Килде шунда Садыйк - комиссар.

Ут йөрәкле батыр, бөркет-агитатор,
Тугры сүзле Садыйк - большевик.
Сөйгән халкы өчен, бирде бөтен көчен,
Искә алыйк аны, баш иеп!

Кокушкино каеннары

Кокушкинские березы

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН *сүзләре*





1976 ел

Юл буенда үскән ак каеннар
Ниләр сөйли икән соң миңа;
Каеннарның хикәясен тыңлап,
Баш иргә киләм мин монда.

Бу каеннар гади каен түгел,
Аның белән алар сөйләшкән.
Башкайларын иеп, шаулый-шаулый,
Озатканнар аны көрәшкә.

Шушы юлдан ничә кабат узган.
Эзләренең тоям җылысын;
Ленин белән киңәшергә киләм,
Хисләремнең алып олысын.

Яшь чагым - гүзәл чагым

Молодость прекрасна

Зиннәт ВӘЛИ *сүзләре*

Tempo di Marcia, vigoroso.





Мәңге туган яшь илемә
Охшатам яшьлегемне.
Яшь чагым - гүзәл чагым,
Әйләнеп карыйм сиңа.
Горур булып үсәргә,
Дөрләп, янып яшәргә.
А...
Горур булып үсәргә,
Дөрләп, янып яшәргә.

Еллар яшьлеге - яздан да,
Гүзәл минем яшьлегем.
Яшь чагым - гүзәл чагым,
Сокланып карыйм сиңа.
Сокланып карыйм сиңа,
Җырларым җырлыйм сиңа.
А...
Сокланып карыйм сиңа,
Җырларым җырлыйм сиңа.

Зур минем куанычым,
Бәхетле киләчәгем.
Яшь чагым - гүзәл чагым,
Бүләгем ил халкына.
Дәртле яшьлек ялкыным,
Килер көннәр хакына.
А...
Дәртле яшьлек ялкыным,
Килер көннәр хакына.

Дусларым

Мои друзья

Илсөяр ГАНИЕВА *сүзләре*





1962 ел

Күзгә җилләр ачы була диеп,
Курыкмаслар асыл кошларым.
Җилләр исә диеп, камыш булып
Сыгылмаслар минем дусларым.

К у ш ы м т а:
Җилфердәтеп шаян җилләр иссә
Чайкалдырып агач башларын,
Ярсу җилләр кебек аямыйча
Ташлап китмәс минем дусларым. } 2 тапкыр

Дусларга таянам көрәшләрдә,
Арыган-талган чакта кайгырмам.
Яшәү өчен миңа көч бирүче
Якын дусларымнан аерылмам.
К у ш ы м т а.

Юлларымда якты йолдыз булып
Юлдаш булды якын дусларым.
Дуслар китсә - урынын дошман ала,
Аерылмагыз, якын дусларым!
К у ш ы м т а.

Артиллерист Гыйлфан

Артиллерист Гильфан

Сибгат ХӘКИМ *сүзләре*

Tempo di Marche





1965 ел

Кулларын ул тезләренә салган,
Кулларында шундый тамырлар:
Күз төшерү белән карт солдатлар, } 2 тапкыр
Бергә узган юлны таныйрлар.

Уйнатты ил азатлыгы өчен
Кулларында авыр тупларны.
Туплар, туплар дүрт ел буе җирдә } 2 тапкыр
Белмәделәр һич тә туктауны.

Тәрәзәдә кичке шәфәкъ яна,
Менә бит ул, яшьлек, син кайда;
Кичке шәфәкъ артиллерия утын } 2 тапкыр
Хәтерләтеп яна Гыйлфанга.

Бар микән шул шәфәкъ нурларына
Күп караучы кеше Гыйлфаннан,
Үткән гомер үкенечле түгел: } 2 тапкыр
Сау, исән-сау булып Ил калган.

Челтәрле күпер

Кружевной мост

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА *сүзләре*



Челтәрле күпергә кадәр
Озата барган идем.
Бер ялгыз каен янында } 2 тапкыр
Аерылып калган идем.

Күпер кичеп киттең ерак,
Көнбатышка юл алдың.
Утлы сугыш кырларында } 2 тапкыр
Бер хәбәрсез югалдың.

Челтәрле күпергә киләм,
Сине сагынган саен.
Янында бер имән үскән, } 2 тапкыр
Ялгыз түгел ак каен.

Сагышлардан җыр юата,
Җырлыйм мин күңелем тулгач.
Авыр кайгылар да үтә,
Ил белән бергә булгач.
Ялгызлык - ятимлек түгел,
Ил белән бергә булгач.

Көтәм һаман үзеңне (Ослан таулары биек)

Жду тебя всегда (Высоки Услонские горы)

Мидхәт МИНШИН *сүзләре*




Кабатлау өчен
е - ге - нә ме - неп, ка - рап кал - дым ү - зең - не,
а - лал - мый - ча кү - зем - не.
л.р.
Coda
Һәй - тәм бө - тен
rit.
Andante
mp
p
дөнь - я - га — туг - ры - лык - лы мин а - ңа.

Гомерлеккә пар диден,
Алып кайттың пар атта.
Өлгермәдем туйганчы
Күзләреңә карап та.

К у ш ы м т а:
Ослан таулары биек,
Иң биегенә менеп,
Карап калдым үзеңне,
Алалмыйча күземне.
(2 тапкыр)

Үстең Идел ярында,
Кабереӊ Берлин янында.
Килде бары хәбәрең
Өзелеп көткән ярыңа.

К у ш ы м т а:
Ослан таулары биек,
Иң биегенә менеп
Көтәм һаман үзеңне,
Никтер өмет өзелми.
Ослан таулары биек,
Иң биегенә менеп,
Әйтәм бөтен дөньяга -
Тугрылыклы мин аңа.

Авылдашлар

Односельчане

К 40-летию Победы

Кояш Тимбикова *сүзләре*




mf
тек бер-гә а-выр су-гыш чо - рын - яшь - ле күз- ләр, җы-е-рыл-ган каш - лар... Җи -
mp
Кабатлау өчен
ңү без-гә җи-ңел би-рел-мә-де, ча - ла-рып кайт-ты яшь-яшь баш - лар. Җи -
mf
Тәмамлау өчен
mf
//рып кайт-ты яшь - яшь баш - лар. //Ә -



Тормыш юлы үргә күтәрелсә,
Горурлыктан күккә чөелә башлар.
Күңел тоя әмма: зур уңышлар
Сездән килә безгә, авылдашлар.
Кичтек бергә авыр сугыш чорын -
Яшьле күзләр, җыерылган кашлар...
Җиңү безгә җиңел бирелмәде, -
Чаларып кайтты яшь-яшь башлар.

Әле дә була күңел сүнгән чаклар,
Моңсуланып кала карашлар.
Ярый әле сез бар бу дөньяда!
Таянырга сез бар, авылдашлар!
Эшләрегез гел уң булып торсын,
Телим сезгә якты язмышлар.
Сезнең бәхет безнең бәхет бит ул,
Бәхетле булыгыз, авылдашлар!
Мең-мең рәхмәт сезгә, авылдашлар!

Сагыну балладасы

Баллада "Томление"

Гали ХУҖИ *сүзләре*





Сугышка сез чыгып киткәндә,
Әле без калганбыз бишектә.
Инде һич оныта алмыйбыз
Без сезне ничек тә, ничек тә.
Без сезне ничек тә, ничек тә.

Тимерче учагың сүнмәгән,
Ул гел көтә сине, әткәем.
Ил бәхетен сакларга алмашка
Кадерләп үстерде Илкәем.
Кадерләп үстерде Илкәем.

Каберең кайдадыр билгесез,
Туфрагың күмгәндер үләннәр.
Китмиләр күңелдән беркайчан
Ил өчен көрәшеп үлгәннәр.
Ил өчен көрәшеп үлгәннәр.

Атам сулышы (Төшләремә кереп иркәлә)

Дыхание отца

Мансур ШИҺАПОВ *сүзләре*




ff
кә төш-сен та-гын, әт - кәй бәгъ - рем
f
f
бер кат, ба - ры, ба - ры бер
mf
p
кат, төш-лә-ре-мә ке - реп
pp
1.
2.
ир - кә - лә.
//лә.
1972 ел

Язгы моңда чишмә тавышыннан
Әткәм сулышы күк, моң килә.
Сабый бала чагым,
Данлы Җиңү көне.

Искә төшсен тагын,
Әткәй бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

Аяз күктә янган йолдызларның
Тыныч җиргә нуры сирпелә.
Шат илемдәй балкып,
Олы юлга чыксам,

Өстәр өчен ялкын,
Әткәй, бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

Безнең буын

Наше поколение

Марсель ГАЛИЕВ *сүзләре*




1.
2.
кош ке-бек я-тып кал-ган. Я-ра-лан-//ган. Ә-
ти-ләр нең саф-ла-ры-на со-ңар-ган-быз. Со-
submp
ңар-ган-быз, лә-кин я-ңа кө-рәш-ләр-гә үз ва-кы-тын-да без
Meno mosso
Tempo I
ту-ган-быз. Без ту-ган-быз.
1977 ел

Сабантуйда, көрәш барган мәйданнардан
Сугыш җиле әтиләрне йолкып алган.
Сөлгеләре яшел чирәм өсләрендә
Яраланган аккош кебек ятып калган.

Яраланган ирләр байрак үпкән чакта,
Фанфаралар кояшкача сузылганда,
Җырлаганда Җиңү җырын бер сулыштан,
Без туганбыз, без туганбыз - сугыш тынган.

Әтиләрнең сафларына соңарганбыз.
Соңарганбыз, ләкин яңа көрәшләргә
Үз вакытында туганбыз.
Без туганбыз.

Белеп торсыннар

Пусть знают

Риза ИШМОРАТ *сүзләре*





Һөҗүм итсәләр дошман яулары,
Яндырабыз, дип якты дөньяны,
Ут ташкыныдай ташланырбыз без;
Белеп торсыннар, белеп торсыннар:
Ватан сагында - Ватан солдаты.

Илебез халкын җирдән юк итү -
Явыз дошманның кара максаты.
Юл куймабыз без, илбасарларга;
Белеп торсыннар, белеп торсыннар:
Ватан сагында - бөтен Ил халкы.

Көрәштә алган бәхетебезне
Яндырмас өчен дошман утыннан
Ут ташкыныдай ташланырбыз без;
Белеп торсыннар, белеп торсыннар:
Тынычлык яклы - бар дөнья халкы.

Колонияләр җимерелә

Рушатся колонии

Сибгат ХӘКИМ *сүзләре*

Andante, marciale





Колонияләр иңри көн саен,
Сафка тезелә туганнар.
Шартлап өзелә тимер богаулар,
Авыр еллар кими көн саен. } 2 тапкыр

Кешеләрдән кайчак сорыйм мин:
"Нигә бу җир сабырсыз?"
Бер көне юк аның давылсыз,
Белмим җирнең мондый чорын мин. } 2 тапкыр

Менә Конго, менә Алжиры...
Уйный Ирек быргысы...
Колонияләрнең дип,соңгысы,
Хәбәр итәр бер көн таң җиле. } 2 тапкыр

Уйламадым

Не думал(а)...

Хәтимә ЗӘЛӘЕВА *сүзләре*




дип.
Сау - бул - лаш - кан
чак - та уй - ла -
*) кабатлау өчен
ма - дым
соң - ны тап - кыр
ку - лым
би - рәм



Уйламадым, дустым, уйламадым,
Соңгы тапкыр сине күрәм дип.
Саубуллашкан чакта уйламадым
Соңгы тапкыр кулым бирәм дип.

Нигә киттең, дустым, нигә киттең,
Нигә ялгызымны калдырдың.
Нигә минем моңсу йөрәгемә
Сүнми торган утлар яндырдың.

Юанырмы күңелем, юанырмы,
Бергә булган вакытларны уйласам,
Тынычланыр микән бу йөрәгем,
Сине сагынып җырлар җырласам.

Газиз җыры
"Күк капусы ачылса" спектакленнән
Песня Газиза
из спектакля "Если улыбнется счастье"

Хәй ВАХИТ *сүзләре*

Tempo di Tango




күз ал-дым-да йөр-мә-сәң-дә, йө-ри-сең кү-ңе-лем-дә.
f
Я-на ми-нем йө-рә-гем, ө-зе-лә-дер ү-зә-гем,
әй-тел-ми-чә ка-лыр ми-кән ин-де әй-тер сүз-лә-
Кабатлау өчен
Тәмамлау өчен
Coda
рем.
//рем.
//рем.



1967 ел

Йөрәгемдә ташкан хисләр,
Тулыр да бер, түгелер дә,
Күз алдымда йөрмәсәңдә,
Йөрисең күңелемдә.
　　Яна минем йөрәгем,
　　Өзеләдер өзәгем,
　　Әйтелмичә калыр микән инде
　　Әйтер сүзләрем.

Кердең дә син күңелемә,
Былбылым булып сайрадың.
Сине генә, тик бер сине
Гомерлеккә сайладым.
　　Бәхетемне эзләдем,
　　Өметемне эзмәдем.
　　Таң атканчы сөйләсәм дә, бетмәс
　　Әйтер сүзләрем.

Аерылмаска сөйгән ярым,
Тик син генә, бер син генә.
Күләгәңнән күзем алмыйм,
Үзең белмисең генә.
　　Яна минем йөрәгем,
　　Өзгәләнә үзәгем.
　　Әйтелмичә калыр микән инде
　　Әйтер сүзләрем.

Кил бүген!

Приди сегодня!

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*




A tempo
ген! Ки - лер сеӊ дип, ки - лер- сеӊ-дип, кө - тә күӊ(е) лем,
1.2.
кил Сөм - бе- лем, кил син, кил бү - ген!
3.
//ген!
rit.

Бакчаларда сандугачлар
Сайрашалар кич-иртән;
Кошлар да синең исемеңне
Әйтәләр төсле, иркәм...

Килерсең дип, килерсең дип, көтә күңелем,
Кил, Сөмбелем, кил син, кил бүген!.. } 2 тапкыр

Нишлим икән, күз алдымда
Бер рәсем көлеп тора;
Рәсемдәге күк күзләрне
Күрәсем килеп тора...

Килерсең дип, килерсең дип, көтә күңелем,
Кил, Сөмбелем, кил син, кил бүген!.. } 2 тапкыр

Берәүгә дә әйткәнем юк
Йөрәгемдәге серне:
Тормышымның сандугачы
Итәсем килә сине!..

Килерсең дип, килерсең дип, көтә күңелем,
Кил, Сөмбелем, кил син, кил бүген!.. } 2 тапкыр

Сагыну вальсы

Вальс "Томление"

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*



Иртән торсам, кичен ятсам, } 2 тапкыр
Сине уйлыйсым килә.
Януымны-көюемне
Җырда җырлыйсым килә.
А...

Төннәр буе уйлап ятам. } 2 тапкыр
Уйласам, уйга батам.
Үзәгемнең өзелүен
Җырлар җырлап юатам.

Йөрәк җырларымны җырлыйм, } 2 тапкыр
Ишетәсең микән, иркәм?
Син дә шулай, минем кебек, } 2 тапкыр
Көн дә сагынасың микән?..

Синең елмаюларың

Твоя улыбка

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*





1955 ел

Җилгә каршы барганда да,
Җиңеләя юлларым.
Әгәр исләремә төшсә
Синең елмаюларың.
Әгәр исләремә төшсә
Синең елмаюларың.
Әгәр исләремә төшсә
Синең елмаюларың!

Син генә туктата аласың
Йөрәгем януларын.
Күңелемдәге бозны эретә
Синең елмаюларың.
Күңелемдәге бозны эретә
Синең елмаюларың.
Күңелемдәге бозны эретә
Синең елмаюларың!

Үземне үзем онытсам да,
Онытмыйм мин син барын.
Йолдызларга ямь бирә
Синең елмаюларың.
Йолдызларга ямь бирә
Синең елмаюларың.
Йолдызларга ямь бирә
Синең елмаюларың!

Төн уртасында уянып
Тынгы бирми уйларым.
Китми иляһи күз алдыннан
Синең елмаюларың.
Китми иляһи күз алдыннан
Синең елмаюларың.
Китми иляһи күз алдыннан
Синең елмаюларың!

Илдарым

Мой Ильдар

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА *сүзләре*





1958 ел.

Еллар үтә, еллар үтә,
Күңелкәем сине көтә.
Көтмә, күңел, көтмә күңел,
Кавышулар мөмкин түгел.

К у ш ы м т а:

Илдарым, Илдарым,
Булалмадың сөйгән ярым. } 2 тапкыр

Гомер уза, гомер уза,
Сине уйлап йөрәк сыза.
Никтер һаман, никтер һаман
Юллар бергә килер сыман.

К у ш ы м т а:

Илдарым, Илдарым,
Булалмадың сөйгән ярым. } 2 тапкыр

Күзләреңне күзләмим

Не ищу взгляда твоего

Мостафа НОГМАН *сүзләре*




гөл-лә-рең бир-сәң и - кән.
Са-гын-ган ми-нут - ла-рым - да
Кабатлау өчен
CODA
poco a poco dim.
аш-кы-нып кил-сәң и - кән.
//аш - кы-нып кил-сәң и - кән,
poco a poco dim.
f
аш-кы-ныш кил-сәң и - кән,
аш-кы-ныш кил-сәң и - кән.
rit.
f

Күзләреңне, күзләреңне,
Күзләреңне күзләмим.
Мин матурлыгыңны синең
Күзләреңнән эзләмим.

К у ш ы м т а:
Алларың алсаң икән,
Гөлләрең бирсәң икән.
Сагынган минутларымда
Ашкынып килсәң икән. } 2 тапкыр

Күзләреңне күзләмим дип,
Алдый гына башладым.
Күз алдымнан китми бердә
Ягымлы карашларың.
К у ш ы м т а.

Гөл сулары сибәр идем
Син йөргән эзләреңә.
Бар матурлыкны җыйгансың
Сихерле күзләреңә.

К у ш ы м т а:
Алларың алсаң икән,
Гөлләрең бирсәң икән.
Сагынган минутларымда
Ашкынып килсәң икән, } 2 тапкыр
Ашкынып килсәң икән,
Ашкынып килсәң икән.

Ничә еллар инде (Кайда син?)

Уж сколько лет... (Где же ты?)

Зия КУЛЬБЕКОВ *сүзләре*

Tempo di Valse




я - на бу йө - рәк? Көтәм си - не, һа - ман
кө - тәм мин. А...
А... Көтәм си - не, ир -
1.2.
кәм, кай - - да син?



1964 ел

Ничә еллар инде
Киткән кошлар килде,
Көтәм сине, иркәм, кайда син?
Хатларың да сирәк,
Ник яна бу йөрәк?
Көтәм сине, һаман көтәм мин.
А...
Көтәм сине, иркәм, кайда син?

Киттең дә, югалдың.
Япа-ялгыз калдым.
Таштыр әллә синең йөрәгең?
Җилләр дә юк төсле,
Нигә болай көчле
Дулкынлана ярсу йөрәгем?
А...
Таштыр әллә синең йөрәгең?

Шаулап су акканда,
Алсу таң атканда
Кайтсаң, иркәм, каршы алырмын.
Сине көтә-көтә
Яшь гомерем үтә,
Нигә инде ялгыз калдырдың?!
А...
Кайтсаң, иркәм, каршы алырмын.

Шаяным

Моя шалунья

Хәниф МӨХӘММӘТҖАНОВ *сүзләре*





1959 ел

Шаян килеш күрдем сине,
Тагын күрәсем килә.
Нигә алай шукланасың?
Шуны беләсем килә.

Шаянланып бер елмайсаң
Чокырлана бит алмаң.
Шаян йөзләреңә карап
Күреп туя алмый - сокланам.

Буең зифа, йөзең шаян,
Күз карашың сөйкемле.
Бизисең син бөтен дөньяны
Күктә янган йолдыз шикелле.

Шаянланып бер елмайсаң,
Таратасың көн яктысын.
Бар йолдыздан да якты син
Көндезен дә якты балкыйсың.

Кабат сагынма икән

Вновь не томись

Равил ФӘЙЗУЛЛИН *сүзләре*





1971 ел

Бәхетле булып, таңга кадәр
Йөргән идек икәү бергә без.
Кавышырга да өлгермичә, } 2 тапкыр
Аерылышкан икәнбез.

Без яраткан ул ләйсәннәр
Кабатланмас микәнни?
Бу йөрәкләр өзгәләнеп } 2 тапкыр
Кабат янмас микәнни?

Күзгә соңгы чәчәкләргә
Саксыз кагылма икән.
Үзең теләп бер хушлашкач, } 2 тапкыр
Кабат сагынма икән.

Дилбәр

Дильбар

Гамир НАСЫРЫЙ *сүзләре*



1957 ел

Күзем төште бер чибәргә,
Шомырт күзле Дилбәргә,
Йөрәгемдәге серемне
Белмим кемгә сөйләргә. } 2 тапкыр

Аклы ситца күлмәгеңне
Кигәнеңне күрмәдем.
Яшерен сөю белән сөйдем,
Сөйгәнемне белмәдең. } 2 тапкыр

Күз алалмыйм шул чибәрдән,
Алсу йөзле Дилбәрдән.
Дилбәрнең күңеле кемдә дип
Сорыйм икән кемнәрдән. } 2 тапкыр

Кызарып кояш чыкканда
Алсулана пәрдәләр.
"Уф" дигәннәрнең мәгънәсен
Ник аңламый бәндәләр. } 2 тапкыр

Ак каеннар шаулый болында

Шумят в долине березы

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*





Ак каеннар шаулый болында
Әкрен генә җилләр искәндә.
Нурлы йөзең искә төшкәндә, } 2 тапкыр
Сагыну хисе ташый җырымда.

Тау битендә, чишмә буенда
Ал чәчәкләр йөгергән төсле.
Синнән хәбәр китергән төсле } 2 тапкыр
Ак каеннар шаулый болында.

Ямьле күлнең зәңгәр суында
Ялгыз калган бер аккош йөзә.
Үзәккәемне өзә, өзә } 2 тапкыр
Ак каеннар шаулый болында.

Синең күзләрең

Твои глаза

Зия КУЛЬБЕКОВ *сүзләре*



1964 ел

Әйтче, иркәм, синең шаян күзләр,
Нигә болай артык ягымлы?
Зәңгәр күктә янган йолдыз кебек,
Ягымлы да, утлы, ялкынлы.

Күлгә төшкән шаян йолдыз кебек,
Шаярмачы күңелем күгендә.
Якты нурлар тама күзләреңнән,
Нинди серләр йөрәк түрендә?

Бөдрә талдай бөдрә чәчләреңне,
Таң җилләре сөеп тарасын.
Һаман яшереп эчке серләреңне,
Зурайтмачы йөрәк ярасын.

Азнакай үрләре

Азнакаевские высоты

Шәриф БИККОЛ *сүзләре*





Ераклардан карап киләм -
карап киләм
Азнакай үрләренә.
Күңелләрем ник талпына,
Күңелләрем ник талпына -
Төшендер серләренә.

Сукмак салдым, юллар ярдым -
юллар ярдым
Азнакай үрләренә.
Мәңге чыкмас булып кердең,
Мәңге чыкмас булып кердең
Йөрәгем түрләренә.

Яллар итми күтәреләм -
күтәреләм
Азнакай үрләренә.
Җаның булса, зарыктырма,
Җаның булса, зарыктырма
Бер авыз сүзләреңә.

Чыкты лимон сарылары -
сарылары
Сагышлы йөзләремә.
Тартыла да тора күңел,
Тартыла да тора күңел
Азнакай үрләренә.

Яңа ел теләкләре

Новогодние пожелания

Частушки

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*





1957 ел

Эш сөюче дусларга без
Зур уңышлар телибез;
Күңелле җырлар җырлыйбыз, } 2 тапкыр
Мактыйбыз, хөрмәтлибез.

Яшьләр эштә дан алсыннар,
Батырлар саны артсын;
Һәр көн саен туган илдә } 2 тапкыр
Матурлык таңы атсын!..

Егетләргә тиң кәләшләр
Өлгереп кенә торсын;
Безнең алдынгы кызларга } 2 тапкыр
Егетләр лаек булсын.

Көнче, ялкау, ялагайның
Күлләре саексыннар;
Исерекләр айнысыннар. } 2 тапкыр
Шешәдән аерылсыннар!..

Шаулап үссен яшь каеннар
Себерке ясар өчен,
Бюрократларны, чүп кебек, } 2 тапкыр
Себереп ташлар өчен!..

Чиста булсын авыл, шәһәр,
Һәрбер урам, һәр мәйдан;
Җәмгыятьне борчымасын } 2 тапкыр
Хулиган дигән хайван!..

Намуслыларның юлына
Бәхет йөгереп чыксын;
Каракларга, бандитларга } 2 тапкыр
Бүсер авыруы йоксын!..

Күңелем нидер эзләнә

Душа что-то ищет

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*




дә,
синең ал - да тез-лә - нә.
Аш-кы - нып ти бә йө - рәк,
дул - кын ке-бек ур - гы -
ла.
Жы - лы - га нур ел-ма - я,



1962 ел

Күңелем нидер эзләнә,
Никтер түземсезләнә.
Баш ими беркемгә дә,
Синең алда тезләнә.

Ашкынып тибә йөрәк,
Дулкын кебек ургыла.
Җылыга нур елмая
Бер карасаң ни була.

Нур көткән кебек иртән,
Елмая күз көткәнгә.
Күзләреңнән дә бигрәк
Елмаюыңны көтәм, иркәм.

Әлмәтем - мәхәббәтем

Альметьевск - любовь моя

Сажидә СӨЛӘЙМАНОВА *сүзләре*





1978 ел

Әлмәт яклары якты,
Чакрым саен маяклы.
Әллә нигә, әллә нигә
Якын иттем бу якны.

К у ш ы м т а:
Әлмәтем, әй, Әлмәтем,
Син минем яшьлек дәртем,
Синдә җан сөйгән хезмәтем,
Бәхетем, мәхәббәтем.

Дала җиле искәндә,
Иртәләрдә, кичләрдә,
Җир астында кара алтын
Тынгы бирми хисләргә.
К у ш ы м т а.

Вышкалар басты сафка,
Тулган ай тора сакта.
Зәй буена кил син, иркәм,
Фонтаннар аткан чакта!
К у ш ы м т а.

Гүзәл Москва

Прекрасная Москва

к 800-летию

Әхмәт ЕРИКӘЙ *сүзләре*





Нурлар сибелгән
Бульварларыңда,
Яшьлек бөркелгән } 2 тапкыр
Урамнарыңда.
    Яшең сигез йөз,
    Үзең нинди яшь.
    Бәхетле йолдыз
    Сиңа чын юлдаш.

Байрагың җилдә
Җилфердәп тора,
Яңа җиңүгә } 2 тапкыр
Алга чакыра.
    Шау килә тормыш
    Бәхетле илдә.
    Яңа киләчәк } 2тапкыр
    Елмая безгә.

Тукайга (Тукай васыяте)

К Тукаю (Завещание Тукая)

Сибгат ХӘКИМ *сүзләре*





Мәктәбемдә, телемдә Тукай,
Тукайдагы кебек тел кайда?
Мең елдан соң да бер синең, Илем,
Кайтасыңны беләм Тукайга.
} 2 тапкыр

Төшләргә дә керде бу Тукай,
Аны уйлап узды Тукайлар.
Мин аңладым: безнең гомерләрдә,
Язмышларда икән Тукайлар.

Һәйкәлләрен күрдем Тукайның,
Һаман шаһит, шаһит мин моңа.
Тукай васыять иткән туган телең
Әйләнгәнен күрдем мин җырга.
} 2 тапкыр

Бик сагынган чаклар була сине

Бывает грустно очень без тебя

к 100-летию Г. Тукая

Сибгат ХӘКИМ *сүзләре*




mf
Ай күр-де дә, ко-яш ал-ды си-не, бул-дың биг-рәк
rit.
A tempo
mp
